## ЗАДАНИЯ ДЛЯ 8-9 КЛАССОВ

**I.Бирелгән сүзләрне туры тәртипкә салып, җөмлә төзеп языгыз, тыныш билгеләрен куегыз.** (10 балл)

яшәргә итеп кирәк дөньяда шундый
үлмәслек үлгәннән булсын да соң
шунда максаты яшәүнең түгелмени бөтен *(Муса Җәлил)*

**II.Җөмләдә фигыльләрне табып күчереп алыгыз һәм нәрсә белән төрләнгәнен языгыз.**(10 балл)

Зариф снаряд шартлавыннан йөгергән һава дулкынының йөзенә бәрелүен сизә. *(Әмирхан Еники)*

III. **Җөмләнең баш кисәге булган хәбәргә билгеләмә бирегез, төрләрен билгеләгез, һәрберсенә мисаллар китерегез.**(15 балл)

IV. *Укытучылар***сүзеннән исем сүз төркеменә караган төрки-татар чыгышлы 10 яңа сүз уйлап языгыз.** (10 балл)

**V.Повесть жанры, аңа хас төп үзенчәлекләр. Үз фикерегезне дәлилле итеп языгыз, һәр жанрга бәйле әсәрләр нигезендә раслагыз**. (15 балл)

**VI. МӘ.Еники иҗаты турынданиләр беләсез? Әдәби әсәрләре, жанрлар, күтәрелгән тема-проблемалар, геройлары. Үз фикерегезне дәлилле итеп языгыз, шагыйрьнең әсәрләреннән мисаллар белән раслагыз.** (10 балл)

**VII. М.Җәлил яки Ф.Кәримнең үзегез теләгән бер шигыренә анализ ясагыз. Үз фикерегезне дәлилле итеп языгыз, шушы чорда иҗат ителгән әсәрләр мисалында раслагыз**. (10 балл)

**VIII. «Бердәмлектә - көч» темасына 150 сүздән артмаган инша языгыз** (20 балл).